| СОВЕТ ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

Шланга авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 февраль 2026 ел 6/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт
турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 29.05.2023 № 27/1 карары белән расланган “Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә” (28.07.2023 №28/2, 18.12.2023 № 33/2, 30.05.2024 № 38/1, 13.12.2024м43/4 редакциясендә) 13 статьяның 3 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"8) әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Шланга авыл җирлеге башлыгы: И.И.Якупов